КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 2 сентябрь г.Казань № 946

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы; 2016 ел, 19 март, 150 нче; 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 18 декабрь, 1008 нче; 2018 ел, 22 март, 161 нче; 2018 ел, 5 июнь, 430 нчы; 2018 ел, 17 декабрь, 1155 нче; 2019 ел, 16 март, 185 нче; 2019 ел, 22 июль, 613 нче; 2020 ел, 11 февраль, 99 нчы; 2020 ел, 11 июль, 575 нче; 2020 ел, 19 август, 710 нчы; 2021 ел, 21 гыйнвар, 19 нчы; 2021 ел, 18 июнь, 476 нчы; 2021 ел, 6 декабрь, 1168 нче; 2022 ел, 22 апрель, 389 нчы; 2022 ел, 1 июнь, 511 нче; 2022 ел, 18 август, 852 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның дәүләт заказчысы функцияләрен үти, дәүләт контрактын төзи һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирә;»;

кырык тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен, аңа даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча гамәлгә ашырыла торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төрен үзгәртү турында белешмәләр кертү тәртибен раслый, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бара;»;

сиксән тугызынчы абзацта «ачык конкурста» сүзләрен «мондый конкурста» сүзләренә алмаштырырга, «аларның эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыра» сүзләрен төшереп калдырырга;

туксан беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы чикләрендә үтә торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төбәкара маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган транспорт чараларының экологик тасвирнамәләренә карата таләпләр билгели;»;

туксан бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру функцияләрен башкара;

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибен (шул исәптән юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яисә туктату турындагы гаризаларын карау тәртибен, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләүдән йә үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләр, әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару өчен нигезләрне) раслый, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгели, үзгәртә һәм гамәлдән чыгара;

автовокзал яки автостанцияләр территориясеннән читтә урнашкан төбәкара яки халыкара маршрут буенча тукталыш пунктларының күрсәткечләрендә мәгълүмат урнаштыруны оештыра;

законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.».

2. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы ундүртенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин